КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 май г.Казань № 443

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары булган җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда түләүләр турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 25 гыйнвар, 32 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары булган җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда түләүләр турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары булган җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда түләүләр турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 25 гыйнвар, 32 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 17 октябрь, 497 нче; 2010 ел, 27 декабрь, 1121 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары булган җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда түләүләр турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу Нигезләмә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы), Россия Федерациясенең бюджет законнары, «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану

өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2006 елның 18 маендагы б-27/б-623 номерлы боерыгы нигезендә эшләнде.»;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану түләүле булып тора. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләүләр җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләүләрдән, җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләүләрдән, аукционда катнашкан өчен җыемнардан гыйбарәт.»;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләү ставкасының конкрет күләме «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 10 пункты нигезендә Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга билгеләнгән тәртиптә лицензия бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларының һәр кишәрлеге буенча аерым Татарстан Республикасының Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

4 бүлекнең исемендә «лицензиядә күрсәтеп үтелгән билгеле бер вакыйгалар барлыкка килгәндә» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1 пунктта «лицензиядә күрсәтеп үтелгән билгеле бер вакыйгалар барлыкка килгәндә» сүзләрен төшереп калдырырга;

бу Нигезләмәнең кушымтасында:

«Доломитлар» юлын төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Балчыклар | 10 | 20 | 30 |
| Гипс | 10 | 20 | 30»; |

«Россия Федерациясе Федераль тау һәм сәнәгать күзәтчелегенең һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2003 елның 26 сентябрендәге б-440 номерлы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2006 елның 18 маендагы б-27/б-623» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин